**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 4 маендагы 1524 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 8 июнендәге 1584 номерлы**
**«Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе**
**гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы булып торган**
**«Казан шәһәренең социаль өлкә учреждениеләрен карап тоту һәм аларга**
**хезмәт күрсәтү департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенә**
**башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү**
**тәртибен раслау турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

«Казан шәһәренең социаль өлкә учреждениеләрен карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенә башка максатларга субсидияләр бирү максатын тулыландыру зарурлыгына бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 8 июнендәге 1584 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы булып торган «Казан шәһәренең социаль өлкә учреждениеләрен карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.2. Әлеге Тәртип Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы булып торган «Казан шәһәренең социаль өлкә учреждениеләрен карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенә (алга таба – учреждение) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан муниципаль йөкләмәгә кертелмәгән башка максатларга субсидияләр (алга таба – максатчан

субсидия, субсидия) бирү күләмен һәм шартларын билгеләү кагыйдәләрен гамәлгә кертә.

Субсидияләр учреждениенең түбәндәге максатларга чыгымнарын финанс белән тәэмин итү максатыннан бирелә:

- Казан шәһәре мәгариф учреждениеләренең, шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең капиталь төзелеш объектларын, капиталь булмаган корылмаларын, төзелмәләрен, конструкцияләрен, төзекләндерү элементларын, коммуналь инфраструктура элементларын капиталь һәм агымдагы ремонтлау буенча чараларны гамәлгә ашыру максатыннан субсидия;

- Казан шәһәре мәгариф учреждениеләрендә, шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсендә капиталь ремонт үткәрү буенча смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендә проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү максатыннан субсидия»;

1.2. 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.4. Максатчан субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C = З1 + З2 + З3 + ... + Зn,$$ биредә:

С – Казан шәһәре мәгариф учреждениеләренең, шулай ук Мәгариф идарәсенең капиталь төзелеш объектларын, капиталь булмаган төзелмәләрен, корылмаларын, конструкцияләрен, төзекләндерү элементларын, коммуналь инфраструктура элементларын капиталь һәм агымдагы ремонтлау буенча чаралар үткәрүгә, муниципаль йөкләмәгә кертелмәгән Казан шәһәре мәгариф учреждениеләре, шулай ук Мәгариф идарәсе биналарына һәм корылмаларына капиталь ремонт үткәрү буенча смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендә проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрүгә субсидия суммасы;

З1, З2, З3, ..., Зn – субсидия күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карар, Казан шәһәре Башкарма комитетының муниципаль программаны раслау турындагы карары белән билгеләнгән очраклардан тыш, Казан шәһәре мәгариф учреждениеләренең, Мәгариф идарәсенең капиталь төзелеш объектларын, капиталь булмаган төзелмәләрен, корылмаларын, конструкцияләрен, төзекләндерү элементларын, коммуналь инфраструктура элементларын капиталь һәм агымдагы ремонтлау буенча чаралар үткәрү, муниципаль йөкләмәгә кертелмәгән һәм учреждение тарафыннан әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә билгеләнгән Казан шәһәре мәгариф учреждениеләре, Мәгариф идарәсе биналарына һәм корылмаларына капиталь

ремонт үткәрү буенча смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендә проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү белән бәйле чыгымнар.

Субсидия күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын алучы буларак максатчан субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән Мәгариф идарәсенә тиешле финанс елына һәм план чорына билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә билгеләнә»;

1.3. 2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.7. Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән субсидияне бирү нәтиҗәсе – Казан шәһәренең ремонтланган мәгариф учреждениеләре, шулай ук Мәгариф идарәсенең ремонтланган биналары саны.

Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән субсидияне бирү нәтиҗәсе – проект документларына Казан шәһәре мәгариф учреждениеләренә, шулай ук Мәгариф идарәсенә капиталь ремонт ясау буенча смета бәясен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә дәүләт экспертизасыннан алынган бәяләмәләр саны».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**